Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 132-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре
буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд
участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Прогресс" һәм "Каенлык" бакчачылык җәмгыятьләре чикләре кушылган җирдә шәһәрнең көнбатыш чигендә урнашкан ноктадан алып бакчачылык җәмгыятьләре арасыннан көньяк-көнчыгышка таба Кутузов урамына кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап Менделеев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Коммунальниклар, Менделеев һәм Степная урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Степная урамы күчәре буйлап көньякка таба Лермонтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Лермонтов урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Шашин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Шашин урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба "Заря" бакчачылык җәмгыятенә кадәр уза, аннары, "Заря" бакчачылык җәмгыятен кертеп, "Заря" һәм "Разведчик" бакчачылык җәмгыятьләре арасыннан Ново-Садовая урамына кадәр уза, алга таба көньякка борыла һәм "Заря" бакчачылык җәмгыятенең көнчыгыш чиге буйлап Ново-Садовая урамы буйлап "Карлен" гараж җәмгыятенә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан гараж җәмгыятьләрен кертеп, Чишмә урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Чишмә һәм Разин урамнарының күчәр сызыклары буйлап көньяк-көнбатышка таба Володарский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны һәм сәнәгать зонасын кертеп, көнчыгышка таба Володарский урамы күчәре буйлап шәһәрнең көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап "Прогресс" һәм "Каенлык" бакчачылык җәмгыятьләре чикләре тоташкан урында шәһәрнең көнбатыш чигендә урнашкан ноктага кадәр уза.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай, Кирлегәч, Куакбаш,

Мөэмин-Каратай, Түбән Чыршылы, Яңа Чыршылы, Ормышлы һәм Аланлык авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлегенең бер өлеше керә, аның чиге Менделеев һәм Кутузов урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кутузов урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Горький урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Горький урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Шашин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шашин урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Кутузов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кутузов урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Яшьләр йорты янында, Кутузов, Крупская урамнары һәм Ленин проспекты кисешкән җирдә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин проспектының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленинград урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Вахитов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Гагарин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Чайковский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Чайковский урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Ирек урамына кадәр уза, аннары көньякка борыла һәм, урман посадкасы территориясен кертеп, "Дәүләт урман фонды" урман посадкасы чиге буйлап Ирек урамы буенча Кыр урамындагы 2 нче йорт янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп (Кыр урамы, Бикчурин урамы, 2 нче Володарский тыкрыгы, Володарский тыкрыгы), "Дәүләт урман фонды" урман посадкасы буйлап көньяк юнәлештә Володарский урамына кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп (Пугачев урамы, Урал урамы), Володарский урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Разин урамына кадәр уза, аннары төньякка борыла, так якта урнашкан йортларны кертеп, Разин урамы күчәре буйлап Чишмә урамына кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Чишмә урамы буйлап бара, Чишмә урамындагы 12 нче йорт янында төньяк-көнбатышка борыла һәм, уң якта урнашкан территорияне кертеп, "Карлен" гараж җәмгыятенә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп (Геофизиклар, Нефтьчеләр һәм Ново-Садовая урамнары буйлап), төньякка таба Ново-Садовая урамындагы 9 нчы йортка

кадәр уза, аннары көнбатышка борыла һәм, "Разведчик" бакчачылык җәмгыятен кертеп, "Заря" һәм "Разведчик" бакчачылык җәмгыятьләре арасыннан Шашин урамына кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шашин урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Лермонтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Лермонтов урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Степная урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Степная урамы күчәре буйлап төньякка таба Степная, Коммунальниклар һәм Менделеев урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы күчәре буйлап Менделеев һәм Кутузов урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лениногорск муниципаль районының Глазово, Ивановка, Писмән һәм Тимәш авыл җирлекләре.

## 3 нче суд участогы

3 нче суд участогы чигенә "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлегенең бер өлеше керә, аның чиге Куйбышев һәм Горький урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Куйбышев урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленинград урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Җиңүнең 50 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 50 еллыгы урамы күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Промышленная урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Промышленная урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Төзүчеләр тыкрыгы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Мурзин урамына кадәр уза, аннары Мурзин урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Базар тыкрыгына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап көньяк-көнчыгышка таба Киров урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, 92 һәм 34 нче йортларны кертеп, Киров урамындагы 90 һәм 92 нче йортлар һәм Кооператив урамындагы 34 һәм 32 нче йортлар арасындагы ишегаллары буйлап уза, аннары, 39 "а" һәм 50 "а" йортларны кертеп, Кооператив урамындагы 39 "а" һәм 37 нче йортлар һәм Колхоз урамындагы 50 "а" һәм 48 нче йортлар арасындагы ишегаллары буйлап уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Краснодонский тыкрыгы күчәре буйлап Письмянская урамына кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәре буйлап Овражная урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Якты урамында урнашкан йортлар буйлап төньяк-көнчыгышка таба бара, Якты урамындагы 37 нче йорт янында көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, шәһәрнең көнчыгыш чиге һәм Бөгелмә тракты

кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көньяк юнәлештә Володарский урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын һәм "Дәүләт урман фонды" урман посадкасын кертеп, Володарский урамы күчәре буйлап көнчыгышка таба Көньяк урамындагы 3 "а" йортка кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, шуннан соң, урман посадкасын кертеп, "Дәүләт урман фонды" урман посадкасы чиге буйлап Бикчурин һәм Кыр урамнарында урнашкан йортлар буйлап төньяк-көнчыгышка таба Ирек урамына кадәр уза, аннары, Ирек урамында урнашкан йортларны кертеп, "Дәүләт урман фонды" урман посадкасы һәм Ирек урамы арасыннан төньяк-көнчыгышка таба Чайковский урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан оешмаларны һәм предприятиеләрне кертеп, Чайковский урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Тукай урамына кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Гагарин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Вахитов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленинград урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Ленин проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин проспекты күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Яшьләр йорты янында, Ленин проспекты һәм Крупская белән Кутузов урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп (11 нче мәктәп), Кутузов урамы күчәре буйлап көнбатышка таба Шашин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шашин урамы күчәре буйлап төньякка таба Тукай урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Горький урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Горький урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Горький һәм Куйбышев урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

3 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лениногорск муниципаль районының Керкәле, Иске Шөгер, Сугышлы, Туктар Урдаласы һәм Шөгер авыл җирлекләре.

**4 нче суд участогы**

4 нче суд участогы чигенә "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлегенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнчыгыш чиге һәм Бөгелмә тракты кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, Сельхозтехника поселогын кертеп, төньяк-көнбатышка таба Якты урамындагы 37 нче йорт янында урнашкан ноктага кадәр

уза, алга таба көньякка борыла һәм, уң якта (Якты урамында) урнашкан йортларны кертеп, Якты урамы буйлап Овражная урамына кадәр уза, аннары Якты урамындагы 17 нче йорт янында төньяк-көнбатышка борыла, уң якта (Письмянская урамында) урнашкан йортларны кертеп, Письмянская урамы күчәре буйлап Краснодонский тыкрыгына кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап бара, алга таба, 48 һәм 37 нче йортларны кертеп, Колхоз урамындагы 48 һәм 50 "а" йортлар һәм Кооператив урамындагы 37 һәм 39 "а" йортлар арасындагы ишегаллары буйлап уза, аннары Кооператив урамындагы 32 һәм 34 нче йортлар һәм Киров урамындагы 90 һәм 92 нче йортлар арасындагы ишегаллары буйлап бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Базар тыкрыгы күчәре буйлап Мурзин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Мурзин урамы күчәре буйлап төньякка таба Төзүчеләр тыкрыгына кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап Промышленная урамына кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, Промышленная урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 50 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 50 еллыгы урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленинград урамы күчәре буйлап Куйбышев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Куйбышев урамы күчәре буйлап Горький урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Горький урамы күчәре буйлап Тукай һәм Горький урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Горький урамы күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Кутузов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Кутузов урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Кутузов урамы күчәре буйлап "Каенлык" бакчачылык җәмгыятенә кадәр бара, аннары шул ук юнәлештә, "Каенлык" бакчачылык җәмгыятен кертеп, "Каенлык" һәм "Прогресс" бакчачылык җәмгыятьләре арасыннан шәһәрнең көнбатыш чигенә кадәр уза, алга таба "Лениногорск шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең көнчыгыш чиге һәм Бөгелмә тракты кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

4 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лениногорск муниципаль районының Зеленая Роща, Кармалка, Мичурин, Яңа Иштирәк, Сарабиккол, Иске Иштирәк һәм Иске Куак авыл җирлекләре.